РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» мая 2023 ел г. Альметьевск № 1520

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Башкарма комитетының аерым
карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 1666 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган коммерциягә карамаган оешма тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 15 апрелендәге 536 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 сентябрендәге 1360 номерлы, 2022 елның 5 сентябрендәге 1888 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидияләр турында мәгълүмат Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә бюджет турында Карар кабул ителгән көннән соң киләсе 15 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла».

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасының инновацион үсеше өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмага субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 1090 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 сентябрендәге 1335 номерлы, 2022 елның 26 сентябрендәге 2103 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Зак. № 305-2000

«3. Субсидияләр турында мәгълүмат Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә бюджет турында карар кабул ителгән көннән соң киләсе 15 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла (бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар)».

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләр тыш) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 27 декабрендәге 1923 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 6 октябрендәге 1904 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидияләр турында мәгълүмат Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә бюджет турында карар кабул ителгән көннән соң киләсе 15 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла (бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар)».

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А. А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов